СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2024 елның «14» февраленнән № 42-328

2023 елда Яңа Чишмә муниципаль районының социаль-икътисади үсеш нәтиҗәләре һәм 2024 елга бурычлары турында

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы В.М. Козловның «2023 елга Яңа Чишмә муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2024 елга бурычлар турында» хисабын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Яңа Чишмә муниципаль районы Советы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы үз вәкаләтләрен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе һәм законнары, Яңа Чишмә муниципаль районы Уставы нигезендә гамәлгә ашырды дип билгеләде. Җирле үзидарә органнары алдында ел дәвамында максималь игътибар таләп иткән берничә төп бурыч тора иде: район бюджетының тулылыгы, социаль, демографик һәм икътисади үсеш перспективаларына бәйле икътисадның реаль секторы үсешендә уңай динамиканы саклап калу.

2023 елда консолидацияләнгән бюджетка 780 млн. сум кергән, шул исәптән үз керемнәре буенча планның үтәлеше 108% тәшкил иткән, үз акчалары белән тәэмин ителеш 35% тәшкил итә. Бюджетның керемнәр буенча үтәлеше бюджет өлкәсендә эшләүчеләргә хезмәт хакын тулысынча түләргә, бюджет өлкәсендә эшләүчеләргә коммуналь түләүләрне һәм район бюджетында каралган башка чыгымнарны башкарырга мөмкинлек бирде. Консолидацияләнгән бюджетның чыгым өлешен үтәү 2022 елга карата 4% үсеш белән 807,5 млн. сум тәшкил итте.

Узган ел Яңа Чишмә муниципаль районы буенча тулай территориаль продукт, 1% үсеш белән, 27 млрд. сумнан артык тәшкил итте.

Тулаем төбәк продукты структурасында төп өлеш нефть тармагына һәм сәнәгатькә туры килә - 80,2%, авыл хуҗалыгына - 9,1%, төзелеш тармагына - 1,9%, транспортировка һәм саклауга - 6%.

Житештерелгән шәхси товар күләме җан башына 2,46 млн. сум тәшкил итте.

Узган елда төп капиталга инвестицияләр күләме якынча 9,5 млрд. сумнан артыграк тәшкил итте.

Шәхси ярдәмче хуҗалыклар белән бергә аграр секторның тулай продукциясе күләме 3,2 млрд. сум тәшкил итте.

Төзелеш программаларын тормышка ашыру буенча зур эш башкарылды. 2023 елда 3,5 мең кв. м. торак төзелде һәм файдалануга тапшырылды. Торакны файдалануга тапшыру буенча куелган план үтәлде.

Спорт объектларының, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният учреждениеләренең матди - техник базасын ныгыту буенча системалы эш алып барылды.

Шуның белән бергә, Яңа Чишмә муниципаль районы Советы халыкның тормыш дәрәҗәсенкүтәрү һәм сыйфатын яхшырту мәсьәләләрендәге кайбер проблемаларга игътибар бирә. Аерым алганда, үлүчеләр санының югары дәрәҗәдә булуы, тууычылар санының кимүе борчу тудыра, яшьләр белән эш көчәйтүне таләп итә, белем бирүнең сыйфатын күтәрү эшен дәвам итәргә кирәк. Салым салу базасын арттыру, район бюджетына өстәмә керем чыганакларын эзләү, яңа эш урыннары булдыру системалы эш таләп итә. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә һәм авылда хуҗалык итүнең кече формаларын үстерүгә аерым игътибар бирергә кирәк.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының даими депутат комиссияләренең фикерләрен исәпкә алып, шулай ук Яңа Чишмә муниципаль районы Уставының район Башлыгының район халкы һәм район Советы алдында хисап тотуы турындагы нигезләмәләрен үтәп, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы В.М. Козловның «2023 елга Яңа Чишмә муниципаль районының социаль-икътисади үсеш нәтиҗәләре һәм 2024 елга бурычлар турында»гы хисабын игътибарга алырга һәм расларга.

2. Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 41 нче утырышында һәм 2024 елның 115 мартына кадәр гражданнар җыеннарында кабул ителгән карарларны үтәү буенча, конкрет срокларын һәм җаваплыларны билгеләп, чаралар планын төзергә һәм расларга, һәм түбәндәге төп бурычларны тормышка ашыруны тәэмин итәргә:

район территориясендә федераль, республика һәм муниципаль программаларны гамәлгә ашыруны тәэмин итүне дәвам итәргә;

- инвесторларны җәлеп итү, яңа производстволар оештыру, район территориясендә инвестицион проектларны гамәлгә ашыру өчен максималь уңай шартлар тудыру буенча эшне дәвам итәргә;

- дәүләт һәм муниципаль милектә булган җир кишәрлекләрен куллану нәтиҗәлелеген, шулай ук муниципаль милек һәм җир кишәрлекләрен муниципаль район мәнфәгатьләрендә, шул исәптән концессион килешүләр буенча арендага бирү нәтиҗәлелеген арттырырга;

- игенчелектә һәм терлекчелектә алдынгы технологияләр кертү буенча чараларны дәвам итү, авыл хуҗалыгы җитештерүчәнлеген арттыру;

- торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләр җыюны 100% тан да ким булмауга ирешергә.

- педагогларның һөнәри үсеше, укучылар белән һөнәри юнәлеш бирү эшен оештыру, сәләтле балалар белән эшне оештыру юлы белән белем бирү учреждениеләренең эш сыйфатын арттыру;

- милли проектларны тормышка ашыру кысаларында һәм туучылар санын арттыру һәм балалар белән матди хәлне яхшырту максатыннан, гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтүнең барлык чараларын да тулы күләмдә тормышка ашыру;

- район халкын, бигрәк тә югары куркынычлы авыруларга дучар булган һәм эшкә яраклы халык категориясен диспансерлаштыру һәм профилактик тикшерү буенча эшне дәвам итәргә;

- 2023 елда прививка ясату компаниясендә район территориясендә олы яшьтәге кешеләргә гриппка каршы вакцинацияне 70% күләмдә үткәрүгә ирешергә;

- яшьләрне яшүсмерләр клубларында катнашуга җәлеп итү һәм яшүсмерләр клублары челтәрен киңәйтү аша гражданлык, патриотизм һәм традицион кыйммәтләргә иярүне тәрбияләү;

- муниципаль район территориясендә яшәүче халыкларның мәдәни үсеше, телләрен, гореф-гадәтләрен һәм традицияләрен саклау өчен тигез шартлар булдырырга;

- Гаилә елына багышланган чараларны план буенча эзлекле рәвештә үткәрү;

- чаралар комплексы үткәрергә, конфессияара мөнәсәбәтләр торышын мониторинглау һәм бәяләргә, конфликтлы ситуацияләргә оператив рәвештә җавап бирергә;

Фәнни-технологик үсеш елы кысаларында билгеләнгән чараларны гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

3. Авыл җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:

- крестьян-фермер хуҗалыкларына һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларга ярдәм итү буенча программаларда һәм грантларда катнашуга халыкны җәлеп итү буенча максатчан эш алып бару;

- Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләре территориясендә гражданнар җыеннары үткәрү аша җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә гражданнарны җәлеп итү, үзара салым кертү һәм үз вакытында җыю, җыеннарда кабул ителгән мәсьәләләрне үтәү буенча эшне дәвам итү;

- торак пунктларны, зиратларны төзекләндерү, яшелләндерү һәм чистарту, җирлек территорияләрендә экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча актив эш алып барырга.

4. Совет аппаратына әлеге утырышта, җирлекләрдә халык белән очрашуларда әйтелгән тәнкыйди искәрмәләрне, тәкъдимнәрне гомумиләштерергә һәм аларны үтәү буенча чаралар күрергә.

5. Район Советының даими комиссияләренә кабул ителгән карарларның үтәлешен контрольдә тотарга.

6. Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының «2023 елда Яңа Чишмә муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2024 елга

бурычлар турында»гы хисабын «Яңа Чишмә хәбәрләре» район газетасында, «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Яңа Чишмә муниципаль
районы Башлыгы В.М. Козлов